РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
Совет
Шереметьевского сельского
поселения Нижнекамского
муниципального района

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
Түбән Кама
муниципаль районы
Ширәмәт авыл җирлеге
Советы

423560, Нижнекамский район,
с. Шереметьевка, ул.Октябрьская площадь, 15

423560, Түбән Кама районы,
Ширәмәт авылы, Октябрь мәйданы урамы, 15

тел./факс (8555) 33-02-72, электронный адрес: Sheremetevskoe.Sp@tatar.ru, сайт: www. sheremetevskoe-sp.ru

РЕШЕНИЕ КАРАР

21.02.2020 ел № 3

**Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районы Ширәмәт авыл җирлеге Советының 2012 елның 24 декабрендәге 31 номерлы карарын үз көчен югалткан дип тану турында**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 48 статьясы, Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районы Ширәмәт авыл җирлеге Уставының 62 статьясы нигезендә, Түбән Кама муниципаль районы Советының «Түбән Кама муниципаль районы авыл җирлекләренең җирле үзидарә органнары вәкаләтләренең бер өлешен Түбән Кама муниципаль районы Советына тапшыру турында килешүләрне раслау хакында» 2018 елның 17 маендагы 37 номерлы карарына таянып, Түбән Кама муниципаль районы Советының «Түбән Кама муниципаль районы Советының 2012 елның 20 декабрендә кабул ителгән 68 номерлы « Түбән Кама муниципаль районы муниципаль хезмәткәрләренең коррупцион хокук бозулар кылган өчен җаваплылыгы турында» карарына үзгәрешләр кертү турында» 2020 елның 21 февралендәге 18 номерлы карарын игътибарга алып, Ширәмәт авыл җирлеге Советы карар бирә:

1. Ширәмәт авыл җирлеге Советының 2012 елның 24 декабрендә кабул ителгән 31 номерлы «Түбән Кама муниципаль районы Ширәмәт авыл җирлеге муниципаль хезмәткәрләренең коррупцион хокук бозулар кылган өчен җаваплылыгы турында» карарын үз көчен югалткан дип танырга.
2. Әлеге карарны мәгълүмат стендларында халыкка җиткерергә һәм Ширәмәт авыл җирлеге сайтында урнаштырырга.
3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемә алам.

В.Г. Емельянов